ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОКУВАКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН	ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ КУАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 27 апреле Иске Куак № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 10 июнендәге 11 номерлы карарына үзгәрешләр керту турында

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп, КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 10 июнендәге 11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 10 июнендәге 11 номерлы карарының 1 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Куак авылы Заварыкин урамы, 36, Зеленая урамы 7 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (leninogorsk.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Иске Куак авыл җирлеге башлыгы И.Н. Сушкова